КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 декабрь г.Казань № 1134

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына эшчәнлекнең педагогик төрен күздә тота торган югары белем бирү мәгариф программалары буенча стипен-дияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 май, 338 нче, 2020 ел, 2 октябрь, 901 нче,

2021 ел, 27 гыйнвар, 29 нчы, 2023 ел, 16 август, 982 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына эшчәнлекнең педагогик төрен күздә тота торган югары белем бирү мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктта «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә Федераль казначылыкның территориаль органына муниципаль берәмлек бюджеты акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачылган шәхси счетка» сүзләрен «Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанс органына ачылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының бердәм счетына» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлекләр тарафыннан агымдагы финанс елның беренче 15 эш көне эчендә килешүдә һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертлар калдыкларын әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга юнәлтергә ихтыяҗ булган очракта, муниципаль берәмлек Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Министрлык, муниципаль районнан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елында файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын юнәлдерүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм муниципаль берәмлек арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнелә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин